# ГРАЖДАННАР ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Рече Мәми авыл җирлегенең Малалла авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

25 нче ноябрь 2021 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 25 нче ноябрендә 14 сәгатьтә булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Рече Мәми авыл җирлеге Малалла авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде :

- Малалла авылы территориясен чабу;
- коены төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Рече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

« РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 33 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -23, бу 69,7 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Риза" позициясе өчен гражданнар җыенында 23 катнашучы тавыш бирде; "Каршы" позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены хәл итте:

1.Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Рече Мәми авыл җирлегенең Малалла авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.«Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Малалла авылы территориясендә яшәү урыны һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сумм күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Малалла авылы территориясен чабу;
- коены төзекләндерү һәм моның өчен материаллар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта,аерым мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Кече Мәми авыл җирлеге Башлыгы Е.Н.Алексеева